НАҖАР НӘҖМИ

Сөю сүзләре

Нажар Нәҗми

Нажар Нәҗми 1918 елда Башкортстан-
ың Дүртиле районында ярлы крестьян
семьясында туа. 1947 елда Башкортстан
дәүләт педагогия институтын тәмамлый.
Шагыйрьнең беренче шигырьләре 1937 ел-
да ук газета-журнал битләрендә күренә
башлый.

Нажар Нәҗми, Бөек Ватан сугышыннан
кайткач, хикәяләр һәм очерклар яза.
1950 елда чыккан „Тамчылар“ исемле бе-
ренче шигырьләр җыентыгы аны үзенчә-
лекле лирик шагыйрь итеп танытты. Ул
драматургия һәм әдәби тәрҗемә өлкәсен-
дә дә уңышлы эшләп килә. Соңгы елларда
язылган „Лирика“, „Язгы җыр“, „Көтелмә-
гән яңгыр“ һәм башка китаплары Нәҗмине
Башкортстанның күренекле язучылары
сафына китереп бастырды.

НАҖАР НӘҖМИ

Сөю сүзләре

ШИГЫРЬЛӘР

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1962

* * *

Редакторы
МӘХМҮТ ХӨСӘЕН

Тышлык художнигы
Л. АНИСИМОВ

* * *

ТУГАН ИЛ ТУРЫНДА СҮЗ

Иңләп, буйлап чыга алмаслык үзең,
Кар буранлы, якты кояшлы,
Гайрәтле һәм көчлеләрдән көчле,
Зур адымлы һәм киң колачлы.
Башкаларга, юк, ул охшамаган,
Һәм үзенчә ата таңнары.
Җәйләре — җәй, кышлары — кыш аның,
Көзләре — көз һәм яз — язлары.
Башкаларга, юк, ул охшамаган
Гадәте һәм халкы белән дә,
Урманнары, урамнары белән,
Сулышы белән, холкы белән дә.
Ул ягымлы җылы язы кебек,
Каты — усал кышысымак та,
Кирәк чакта — җәе кебек кайнар,
Көзе кебек бай да, юмарт та.
Сөям аны шундый булганы өчен,
Төрле булган өчен көннәре;
(Әгәр җирдә гел яз гына булса,
Ни язлыгы аның, ни яме?)
Мин аныкы җаным-тәнем белән,
Аның өчен кан да, сулыш та;
Сөям аны һәм төрлечә сөям:
Җәе, кышы, язы булып та.

1957

ТАМЧЫЛАР

ТАМЧЫЛАР

Карт Урал сыртыннан, саркып,
Вак-вак тамчылар,
Көн-төн туктамый, тып та тып,
Ташка тамдылар.

Күпме тумаганнар туып
Үлделәр җирдә,
Һәм күпме кыя ташларын
Кимерде җилләр.

Дөньяда шул вакыт акты
Никадәр сулар,
Ә шул тамчылар тып та тып
Һаман тамдылар.

Тамдылар да... ташның өсте
Төште уелып,
Һәм чыкты шуннан бервакыт
Чишмә ургылып...

...Тау җырчысы — көмеш чишмә
Чылтырап ага,
Ә җырында тамчыларга
Зур дан тарала.

1949

БЕЗНЕҢ УРАМНАРДА

Быел тагын шаулап яфрак ярды
Урамнарда япь-яшь юкәләр;
Туган калабызның шау-шуында
Алар нинди тыныч үсәләр.

Агачлар да кичерә яшьлекне,
Агачлар да монда бәхетле.

Аларга һич яман куллар тими,
Сыйпап кына үтә җилләр дә;
Агачларга да бит тыныч үсү
Мөмкин түгел кайбер җирләрдә...

Агачлар да бездә бәхетле,
Агачлар да кичерә яшьлекне.

1952

КОТЕЛОК

Нинди суларны сирпеп мин
Тын алмый эчтем синнән;
Һәм күпме җирләрне үтеп,
Аерылмас булдың миңа.
Котелогым, котелогым,
Аерылмас булдың миңа.

Күпме аш пешереп синдә,
Кайларда ашамадым;
Күпме җәфалар күрсәм дә,
Мин сине ташламадым.
Котелогым, котелогым,
Мин сине ташламадым.

Утлар яндырган чагында,
Сугардың йөрәгемне;
Син дә белдең кебек минем
Сагынып йөргәнемне.
Котелогым, котелогым,
Сагынып йөргәнемне.

Туган җир суларын эчәм
Сусаган чакларымда;
Ялга туктаганда күрәм:
Син һаман яннарымда.
Котелогым, котелогым,
Син һаман яннарымда.

Кирәк булса, шинель киеп,
Тагармын сине билгә;
Бәлки, тагын күп җирләрдән
Үтәрбез икәү бергә.
Котелогым, котелогым,
Үтәрбез икәү бергә.

1947

ДУСЛАР

Дөнья матур дуслар белән генә,
Дуссыз яшәүче сирәк;
Ләкин дуслар арасында да дусны
Таба белергә кирәк.

1948

МЕДАЛЬ

Күрдем бу бөек сугышның
Иң соңгы күкрәвен дә,
«Берлинны алган өчен» дә
Медаль бар күкрәгемдә.
Җиңүче булып үттем мин
Берлинның урамыннан:
Күрдем американлысын,
Англичан булганын да.
Кайсының йөзенә карадым,
Кайсының ярасына;
Күрдем дошманны, дусны да
Аларның арасында.
Азмы-күпме сугыш күргәч,
Ул шулай була инде:
Барысының да түшләренә
Медальләр куна иде.
Берлин буйлап үтсәләр дә
«Без кемнәр?» дигән төсле;
Ләкин беркемдә юк иде
«Берлинны алган өчен».
Мин белдем фашист өенә
Ни өчен килгәнемне,
Дөньяга күрсәттем ничек
Илемне сөйгәнемне.
Көрәштә җиңгән шикелле,
Хезмәттә җиңә илем;

Океан артыннан кабат
Искәндә сугыш җиле,
Бөек Хезмәттә сулыймын
Артсын дип Ватан көче,
Салмыймын медалемне дә —
«Берлинны алган өчен».

1949

АЛЕКСАНДР МАТРОСОВКА — ПАРОХОДКА ҺӘМ СОЛДАТКА

Агыйделнең дулкыннарын ярып,
Яңгыратып таулар арасын,
«Александр Матросов» бара...
— Саумы, солдат!
Саумы, пароход!
Ул кычкырып борылмага керә,
Көчле тавыш яра һаваны;
Гүя шул чак — ротада барлау,
Әйтерсең, бу — аның җавабы.
Без ятмадык утлы Чернушкиның
Карларында икәү янәшә;
Ләкин сине күреп белмәсәм дә:
«Саумы, солдат дус!» — дип эндәшәм.
Әнә Уфа.
Бүген дә син аннан
Юл башладың ерак арага;
Синең кебек, күпләр үз юлларын
Башлаганнар шушы каладан.
Ераклашкан саен Уфа тавы
Биекләнгән төсле күренә,
Әйтерсең ул синең исемең белән
Горурланып күккә үрелә.
Мин гашыйкмын,
гашыйк булган кебек
Сиңа илемнең һәр кешесе;

Кирәк чакта
Синекедәй булсын
Йөрәгемнең соңгы тибеше.
Мин гашыйкмын сиңа.
Менә бүген
Күтәргәнсең авыр йөкләрне;
Син бит солдат чакта
халкың өчен
Нинди авырлыкны күтәрдең!
Тәү күргәндәй көмеш Агыйделне,
Палубаңнан карыйм сокланып.
Ак дулкыннар «Саумы!» дигәнсыман
Сиңа йөгерәләр туктамый.
Яр башында кызлар яулык болгый,
Дулкынлана кырлар киңлеге —
Синең гомерең шулай яулап алды
Мәхәббәтен Туган илемнең.
Ага саллар... Әнә буксир килә
Баржасына иген тутырып;
Күпләр бүген яңа эшкә бара,
Ялга бара сиңа утырып.
Нинди куәт синдә!
Күтәргәнсең
Күпме кеше, күпме йөкләрне,
Солдат чакта
шул кешеләр өчен
Нинди авырлыкны күтәрдең!
Син каплаган дзот
тынганнан соң
Үткән гомер әле аз гына;
Уолл-стрит шул дзотның утын
Кабызырга уйлый яңадан.
Кирәк булса,
синең подвигыңны
Бездә һәркем, һәркем кабатлар.

Күрәм сине:
              син һаман да сафта —
Пароход та бүген,
              Солдат та.

1949

МИН КИТМӘКЧЕ БУЛДЫМ...

Мостай Кәримгә

Мин гашыйкмын Кавказ дусларыма,
Шигырьләренә мин гашыйкмын;
Үземне дә инде шагыйрьмен дип
Исәпләдем... Ахры, ашыктым.

Бөек Тукай, бүген сиңа ияреп,
Күңелем кошы минем тарсынды;
Мин китмәкче булдым Кавказларга
Уралымнан алып башымны.

Анда һәр тау, авыл саен шагыйрь —
Шигырьләрнең юктыр исәбе;
Анда, дидем, таулар, Кавказ үзе
Шагыйрьләрне шагыйрь итәдер.

Хушлашырга чыктым Уралыма,
Кайда барма — таныш юлларым,
Бөтен күргән хәерле юл тели,
Хәерле юл, диләр, дусларым.

Хәерле юл, диләр, бөтен юллар,
Хәерле юл, диде, карт Урал:
Бүләк итеп бер тау бирәм, диде,
Җаның теләгәнен сайлап ал.

Син ул таудан, диде, юнып-юнып,
Шигырь яса минем көч итеп;
Шуны ерак Кавказ дусларыңа
Алып бар син минем төс итеп.

Шигырь ит син — чишмә бирәм сиңа,
Агачларның сайла зифасын;
Анда кәкүк юктыр — ал тавышын,
Курай моңын, кымыз шифасын.

Шигырь итеп алып бар син анда
Кешеләрнең якты күңелен,
Кыз карашын (беләм, аннан башка
Сиңа яшәү мөмкин түгелен).

Алып бар син — җаның нәрсә тели:
Гөлләр нурын, көзләр сарысын;
Шигырь итә алмасаң, үз җилкәндә
Алып бар син, шагыйрь, барысын...

...Туган җирем, шундый юмартсың син —
Мин күтәреп барын китә алмам;
Син биргәнне гомерем буена да
Шигырь итеп язып бетә алмам.

Әй туган җир, гомер-гомергә
Үзең илһам һәм җыр шагыйрьгә.

1959

ШАГЫЙРЬ ТАВЫШЫ

«Бир кулыңны...»

М. Гафури

Туган илем ерак калган иде:
Яу юллары ятты арага;
Ямансулап тәулар арасында,
Яши идем бер чит калада.

Әйтерсең лә, кинәт минем янга
Килеп керде туган кырларым:
Мәскәү аша Мәҗит Гафуриның
Шигырьләрен йотылып тыңладым.

Соры яңгыр коеп ява иде,
Ята иде урам ялтырап;
Тәрәзә ачтым һәм бу туган тавыш
Урамнарга чыкты яңгырап...

Үтте иңләп Гейне китаплары
Утта янган җирләр аркылы,
Гүя бергә ул шатлана иде
Җиңүенә бөек халкының.

Беләм, аны бер мин генә түгел,
Дөнья ишеткәндер ул чакта;
«Бир Берлинны алган кулыңны!»— дип,
Үпте кебек мине кочаклап.

Кайда барсаң, кайда яшәсәң дә,
Була сиңа иптәш, җан дусың;
Ерак җирләр, сансыз еллар аша
Ишетәсең шагыйрь тавышын.

1949

МЕНДЕМ УРАЛ ТАУ БАШЫНА

Мендем биек Урал тау башына,
Бөркет тора кыя ташында;
Баш очымда балкып яна кояш,
Болыт ята аяк астымда.

Монда җилләр, урман, елгалар да
Берсен-берсе килеп табыша;
Бу җирләрдә йолдыз белән йолдыз,
Таулар белән таулар кавыша.

Мендем биек Урал тау башына,
Җилләр тауга сөйли серләрен;
Шушы инде җил-давыллар кичкән,
Минем туып-үскән җирләрем.

1959

ТУГАН КАЛАМА ҖЫР

Көмеш каеш буган егет кебек,
Агыйделне урап биленә,
Баскансың син Урал сакчысыдай,
Туган Уфам минем, бер генәм.

Хәтеремдә: юл капчыгы асып,
Беренче кат гомерем таңында,
Канатланып күккә менгән кебек,
Менгән идем синең тавыңнан.

Күпме еллар артта калган хәзер,
Тик сизмәдем гомер үткәнен,—
Чөнки мине үзең кебек биек
Тормыш тауларына күтәрдең.

Туган ана улын озаткандай,
Киткән чакта карап каласың;
Кайткан чакта, синерактан күреп,
Кочагыңа тартып аласың.

Бер генә көн күрми торсам да мин
Күңелләрем синсез боега;
Синнән китсәм, хәтта ташларың да
Чәчәк аткан төсле тоела.

Әллә башлап синдә күргәнгәме
Якты гомеремнең яктысын,
Әллә инде синдә эчкәнгәме
Эчкән суларымның татлысын,
Йөрәгемә бигрәк якынсың.

Эштән арып кайткан чакларымда,
Яза алмаган чакта җырларны,
Баскан җирдән сүзләр эзләгәндәй,
Чишә-чишә шигъри уйларны,

Урамнардан үтәм — бары да таныш:
Һәр борылмаң, урам чатларың;
Бары да таныш: хәтта ташларыңның
Беләм кайда, ничек ятканын.

Күз алдымда агачларың үсте,
Биек йортлар тезелеп бастылар;
Күз алдымда кайнар асфальтларың
Мәйдан-урамнарга яттылар.

Бакчаларың чуен койма киде —
Мин аларга карап сокланам.
Һәр чәчәгең мине куандыра,
Һәр бизәгең өчен шатланам.

Сөям, калам, синең шау-шуыңны,
Машиналар, гудок тавышын,
Дим буйларын, җырларыңның моңын,
Агыйделнең тыныч агышын...

Юкәләрең чәчәк аткан чакта,
Җәйге кичтә хуш ис аңкуын,
Йолдызларның яктылыгын күмеп,
Төнге утларыңның балкуын...

Синдә — көч, синдә — хезмәт,
Синдә — кешегә хөрмәт;
Синдә — җыр, синдә — илһам,
Әй Уфам,
Уфам,
Уфам!

1949

КИЧКЕ АГЫЙДЕЛ

Җилкәнсез көймә шикелле,
Ай йөзә талгын гына;
Ай янында җем-җем иткән
Йолдыз да йолдыз гына,—
Ай йөзә ялгыз гына.

Уфа утлары җемелдәп
Идел өстенә төшә;
Әйтерсең, алар сузылып
Агыйдел суын эчә,—
Идел өстенә төшә.

Серләшә кебек бар җиһан,
Бар агачлар тын гына;
Коча кебек Димне Идел
Әкрен генә, шым гына,—
Серләшәләр тын гына.

Балкый монда бар тирә-юнь:
Кайда соң күк, кайда җир?!
Агыйделнең тыны кебек,
Исеп куя җылы җил,—
Әй туган җир, туган җир!

1959

ҺӘЙКӘЛ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Туган җирдә мәңге балкырга
Һәйкәл куйды халкы батырга.

Алдындагы киң мәйданга карап,
Горурланып туган халкына,
Пьедесталда, кулын алга сузып,
Торды һәйкәл урам башында.

Үтте еллар... Һәм батырның туып-
Үскән җире калды ялкында;
Күрде һәйкәл: сөрем ашасыннан
Дошман атлап үтте алдыннан.

Тик ул, һаман зур мәйданга карап,
Горурланып бөек халкына,
Пьедесталда, кулын алга сузып,
Торды шул ук урам башында.

Ә килмешәк, бөтен җирне айкап,
Шәһәр буйлап шашып йөреде;
Һәйкәлне дә күреп: «Урыныннан
Юк итәргә!»— диеп җикерде.

Алып килде солдатларын җыеп,
Һәм батырның сузган кулына
Тимер аркан бәйләп әй тарттырды,
Аудартам дип шушы урыннан.

Ә ул, һаман киң мәйданга карап,
Горурланып бөек халкына,
Пьедесталда, кулын алга сузып,
Басып торды урам башында.

Ул мәңгегә кузгалмасын белеп,
Торды һаман баскан җирендә...
Тик бервакыт, тарта торгач, аның
Китте кулы сынып, зеңелдәп,

Шул секундта өстән суккан кебек,
Җан ачуы белән кизәнеп,
Килмешәкнең нәкъ башына төште
Шул өзелгән зур кул кисәге.

...Ятты дошман урам ташында,
Үлеп аның аяк астында...

Ә ул үзе, киң мәйданга карап,
Горурланып бөек халкына,
Яраланган солдат кебек, һаман
Торды басып урам башында.

Көнчыгыштан кояш белән бергә
Җиңү уты җирдә балкыды;
Кабат нур һәм бәхет белән тулды
Туган-үскән иле батырның.

Алдындагы зур мәйданга карап,
Горурланып бөек халкына,
Пьедесталда, кабат кулын сузып,
Тора һәйкәл урам башында.

1950

ҖИЛКӘН

Басу ята, чиксез диңгез булып,
Дулкынлана арыш сабагы;
Атка атланган, ак күлмәктән берәү
Җилкән кебек килә агарып.

Ул — куплэрнең берсе. Аны күреп,
Дулкынлана басу — як-яклар.
«Син үстердең безне, рәхмәт!» — диеп,
Баш иялэр кебек башаклар.

Ә ул килә... Һаман йөзә кебек
Диңгездәге җилкән шикелле.
Йөзсен әйдә! Ул бит үзе ясый,
Үзе ясый бит ул диңгезне.

1951

ИКЕ ВЫШКА

Ике тауда, бер-берсенә карап,
Ике вышка тора тын гына:
Ә аларның йөрәгендә, төптә
Нефть кайный, нефть ургыла.

Шәһәр балкый тауның итәгендә —
Матурлый ул туган ягымны!
Җем-җем утлар шундый вышкаларның
Йөрәгеннән чыгып кабынды.

Ике вышка — ике гашыйк кебек,
(Гашыйклар да шулай тын тора.)
Ә күпме ут алар йөрәгендә
Һәм күпме көч кайный, ургыла!

1952

БАЛА

Күрше өйдә бер яшь бала елый.
(Безнең өйдә юк бер тавыш-тын.)
Ана йоклый бугай... юк, уянды:
Менә тынды бала... тынды төн.

Бала өчен ана күпме йончый —
Вакытында юньле йокы юк;
Безнең өйдә көнен-төнен тыныч,
Әллә шуңа аның коты юк.

Бала тавышы, матур җыр шикелле,
Ниндидер моң белән тулган ул.
Бала күрмәгән өй — кош сайравын
Ишетмәгән моңсу урман ул.

1952

МИЛӘШ

*Ватан сугышында һәлак
булган агаем истәлегенә*

Безнең йорт ишек алдында,
Бакчада үсә миләш;
Кечкенә идем... утыртты
Аны агаем Гыйләҗ.

Туган туфрагымда аунап
Мин үстем, үсте миләш;
Ил чакыргач, яуга киттем,
Китте агаем Гыйләҗ.

Урап кайттым. Каршы алды
Бакчада үскән миләш.
Мин кайттым... тик кайта алмады
Минем агаем Гыйләҗ.

Язын чәчкәгә төренә,
Ә көзен пешә миләш;
Миләшкә карый да әни
Кабатлый: «Гыйләҗ, Гыйләҗ!»

Җәйге эсседә миләшнең
Төпләре була җиләс;
Мин утырып шигырь язам:
«Рәхмәт, агаем Гыйләҗ».

Кошлар кунып сайраганда
Талпынып куя миләш;
Кошлар да әйтә шикелле:
«Ай рәхмәт сиңа, Гыйләж!»

Авылдан киткән чакларда
Ерактан күренә миләш;
Һәм карап кала шикелле
Минем агаем Гыйләж.

1953

УЙЛАНУЛАР

Җир йөзендә бары да кеше өчен:
Яңгырмы ул, кармы яуса да,
Агач үссә, кошлар сайраса да,
Чәчкә атса, сулар акса да.

Бары да кеше өчен... Ә җир! Ә җир!
Нинди матур үзе, нинди киң.
Шатлыгың да, кайгың да бит шунда —
Туган туфрагыңа нәрсә тиң?

Мәрхәмәтле үзе, бәрәкәтле,
Күпме җыр бар аның хакында;
Ә бит үзе, иксез-чиксез булып,
Ята кеше аягы астында...

Мин дә барам шушы җиргә басып,
Шулай тиеш... гаҗәп берни юк.
Кышкы бер кич менә... искиткеч кич:
Шәһәр өсте җем-җем ут та ут...

Гаҗәп берни дә юк... күбәләк кар
Әкрен генә ява алдыма;
(Чынлап та бит карның бер шавы юк)
Таптап үтәм мин шул карны да...

Җир йөзендә бары да минем өчен,
Туган җирнең мин дә бер улы;
Гаҗәп берни дә юк, ләкин бәхет
Шундый җирнең улы булуы.

1955

ШОБАГА

Кави Нәҗмигә

Шобага тотылды бүген...
Ах, өскә чыкты үлем.
Кеше бар иде, хәзер юк —
Без, хәзер ансыз бүген.
Ах, өскә чыкты үлем!

Адаш идек. Каләмдәшлек
Ничектер туры килгән.
Беребез яшь, ә беребез
Күбрәк дөнья күргән,
Соклангыч яза белгән.

Шобага тотылды бүген...
Ә тышта язгы җилләр,
Тама беренче тамчылар:
«Бу яз Нәҗмисез» диләр,
Ә тышта язгы җилләр.

Йөрәгендә гел җыр иде,
Җырлап һич тынмый иде,
Кайгырырга бер урын юк,
Шатлыклар сыймый иде,
Җырлап һич тынмый иде.

Шобага тотылды бүген
Һәм өскә чыкты үлем.
Ләкин язгы җилләр булып
Ул кабат исә бүген —
Җилләргә тими үлем!

1957

ШУЛДЫР ИНДЕ

25 сентябрь, 1957 ел

Гомернең дә язы, көзе була...
Күптән үтте гомерем язлары;
Баш очымнан инде каңгылдашып
Оча тезелеп кыр казлары.

Быелгы көз шундый җылы килде:
Яланнарда — язгы яшеллек,
Агачларда — чәчкә бөреләре,—
Нәрсәсе бар көз дип әйтерлек?!

Һәрбер чәчкә саен — бал кортлары,
Яшьнәп, күкрәп ява яңгыры.
Болыннарда тездән тикле үлән,
Җуа чыккан, рәхмәт яугыры.

Көзләр дә бит төрле-төрле килә,
Төрле чакта килә язлары;
Очып килә, янә очып китә
Вакытында тик кыр казлары...

Шулдыр инде гомеремнең көзе
Үткән язлар төшкәч хәтергә;
Ләкин кара син быелгы көзгә:
Мөмкинме соң «көз» дип әйтергә?..

МУЕЛ *

Һәр агач үзенчә яши:
Имән, карама, муел.
Тик менә муелга карап
Гаҗәпкә калдым быел.

Язын ап-ак чәчкә атты
(Хуш искә чумды кырлар);
Ләкин соклана-соклана
Чәчкәсен сындырдылар.

Өзгәләнеп, өтәләнеп
Калды урманда муел.
Һәм ул әйтте: «Җитте миннән,
Соңгысы булсын быел.

Әгәр мин чәчәк атмасам,
Һич кул салмаслар иде.
Әгәр җимешем булмаса,
Өзеп алмаслар иде».

Чәчкәсез, җимешсез генә
Яшәргә булды муел:
«Җитте, җитте,— диде кабат,—
Соңгысы булсын быел».

---

* Шомырт.

Көз җиткәч, койды яфрагын,
Һәм кар ябынды кат-кат;
Яз җиткәч тә (ни күрәм мин!),
Ул кабат булган ап-ак.

1957

КЫЗ ҺӘМ ИЛ

Алжир кызы Җәмилә Бухиредка

Булганым юк туган җирләреңдә,
Тик мин күрәм синең күзләреңдә:
Соклангыч нур, моң һәм ямь генә;
Күз алдыма баса туган җирең,
Минем өчен ул син — туган илең,
Туган илең — ул син, Җәмилә.

Нинди уртак сезнең язмыш бүген,
Әйтә сиңа җәфа чиккән илең:
«Әй Җәмиләм, кыю Җәмиләм.»
Җаваплыйсың: «Синең өчен бүген
Берни түгел миңа хәтта үлем,
Туган илем минем, ил генәм.»

Мондый кызны, улны үстергән җир,—
Синең кебек үзе матур бер җыр;
Кол итә алмый җырны беркем дә!
Дошманына ул ут булып ява,
Төрмәләрне төрмәләргә яба,
Хөкемнәрне бирә хөкемгә.

Күргәнем юк туган җирләреңне,
Тик мин алмыйм синнән күзләремне:
Сокландыгч нур синдә, ямь генә;
Күз алдыма баса туган җиреӊ,
Минем өчен ул син — туган илеӊ,
Әлҗәзаир — ул син, Җәмилә!

1958

«ЯЗ! ЯЗ!»— ДИЛӘР

Кайда барма — җирдә яз сулышы...
«Яз! Яз!»— диләр кырлар, урманнар.
«Яз!»— дип, алар бүген матурланып,
Гел яшелдән киенеп куйганнар.

«Яз! Яз!»— диләр бөтен сайрар кошлар
Табигатьнең сихри телендә;
Кошлар! Кошлар! Сезне сайратырлык
Их, язасым килә минем дә....

«Яз! Яз!»— диләр, ә мин: «Язам!»— димен,
«Язам!»— димен урман, кырларга,
«Язам!»— димен шигырь сөйгәннәргә,
«Язам! Язам!»— димен кошларга.

Язның күрке икән нурларда,
Күңел күрке икән җырларда.

1958

КИЧЕР МИНЕ

Муса Җәлилгә

Демблин. Радом. Берлин... Шул юллардан
Алып барды сугыш мине дә
Шул юллардан дошман чигенә-чигенә
Алып киткән икән сине дә.

Бер үк юлда ике төрле язмыш...
Ә мин шунда исән калганмын,—
Әйтерсең лә, дошманнарны куып,
Мин тик сине эзләп барганмын.

Хәтерлимен төрмә коймаларын,
Бәреп кергән тимер капканы;*
Үз күзләрем белән күргәнмен мин,
Үз кулларым белән тотканмын мин
Сине харап иткән балтаны.

Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер —
Синең даның шуңа калганмы?..
Палачларга сине бирмәс өчен,
Кичер мине, соңлап барганмын.

---

* Сүз Муса Җәлил җәзаланган Берлин төрмәсе хакында бара. Мин хезмәт иткән часть Берлин сугышларында шул төрмәгә беренче булып бәреп керде һәм миңа үз хезмәтем буенча шул төрмәдә берничә көн эшләргә туры килгән иде.

ҮПКӘ

Рәсүл Гамзатовка

Якын күргән чакырганны көтми,
Без чакырдык... әллә ни эшләдең:
Безнең якка җилләр исмәдеме,
Киләм дидең дә син, килмәдең.

Якын күреп, әллә ялгыштык,
Әллә юкка хатлар языштык...

Син тауларда туып үскән егет,
Ямансудыр ялан җирләрдә;
Сиңа таулар тапмас идекмени
Төрелгәнен урман, гөлләргә?

Килә дигәч, шигырьләрең кебек
Якын күреп, кызлар көттеләр.
Шикләнмәсен Фатмаң — тау кызлары кебек
Алар безнең тыйнак, иплеләр.

Синең Кавказ сайрар кошларга бай,
Ә без ярлымыни кошларга?
Алар көтеп сайрады да тынды,
Без ялганчы булдык кызларга.

Кунакчыллык, дуска якты чырай
Кергән, дисең, безнең гадәткә;
Нигә, башкорт кунак сыйлаганда
Карап торамыни сәгатькә?

Син килмәдең. Әллә төньяк иле
Салкын, дәртсез булыр диденме?
Я булмаса леки * килә дигәч,
Бала-чага куркыр диденме.

Дәрт дигәндә — безнең мәйданнарда
Тау селкенә егет басканда;
Дагстаның онытылыр иде —
Аларга син тик бер баксаң да.

Урманнарда аю белән алыша
Һәм күтәреп бәрә елт итеп;
Ат өстендә җилеп кош тотмагач,
Егетмени башкорт егете.

Сездә шулай икән... Ә бездә дә
Ир канаты булган — ат бит ул.
Ат өстендә җилеп, җиргә иелеп,
Кыз да үпмәү — бездә ят бит ул.

Сузып бер ерласа, аягүрә
Басып тыңлый Урал таулары;
Һәрбер җыры аның — тулы язмыш,
Шатлыгы да шунда, моң-зары.

Башкорт җырын, үзенеке күреп,
Җырлый ала синең якташың:
«Кайда булмый, ниләр күрми
Ир егеткәй белән ат башы»...

Мактану юк, ходай саклый күрсен,
Андый гадәт безгә хас түгел;

---

* Леки — элек грузиннар аварларны шулай атаганнар.

Ни әйтсәң дә, кеше кеше инде,
Аның бәгъре салкын таш түгел.

Хәтер калды әзрәк шул мәлдә,
Сине фәкать якын күргәнгә.

1958

ҚАЙТУ

Теләк

Окопларда аунап, тиргә батып,
Тузанлы, зур сугыш юлларын
Үтеп, уңган гимнастеркам кебек,
Төссез булыр, бәлки, җырларым.

Күпне күргән солдат
запас патрон
Сала һәр чак капчык төбенә,
Капчыгымда патрон йөрткән кебек,
Туар җырлар йөрде күңелдә.

Қайтам... ләкин сагынып кына түгел
Туган җирне, якын дусларны,
Туган илне өзелеп сагынгандай,
Сагынып кайтам туар җырларны.

Иҗат авыр — үткән походлардай,
Ләкин кирәк солдат булырга;
Мин телимен, гимнастерка кебек,
Хезмәт итеп уңсын шигырьләр.

Сау бул, Веймар!

Сау бул, Веймар!
Сиңа мин ашкынып
Сәяхәтче булып килмәдем,

Үзең күрдең, кулга автомат тотып,
Урамыңа минем кергәнне.
Күңелгә ят соры афишалар
Һәр почмактан миңа карады;
Мин тик кайтыр көннәремне генә
Минут саен синдә санадым.

Һәр узганда синдә карап тордым
Гёте белән Шиллер һәйкәлен;
Һәм әйтәсе килде:
— Эй, генийлар!
Карамагыз өскә гарьләнеп.

Туган җирнең җимерегән күреп,
Сезнең йөрәк, беләм, янадыр;
Кем дә түгел,
Фашист шулай итте
Сез яшәгән шушы каланы.

Сезнең һәйкәл исән калган кебек
Җимергәндә бомба ялкыны,
Исемегез гомергәчә калыр
Күңелендә минем халкымның.

Юлда

Канат куйды кебек ашкыну,
Асфальт буйлап, тынып, мин җиләм;
Үтүчеләр кайда баралар?
Ә мин кайтам, кайтам илемә.

Еллар үтте, ятып эчмәдем
Туган чишмәләрнең суларын.
Еллар үтте, кайтып күрмәдем
Болыннарым, елгам буйларын.

Мин сагындым туган өннәрне,
Әнкәемнең иркә тавышын.
Татымасам иде тагын да
Чит илләрдә булган сагышны.

Берлин урамында уйлар

Берлин сугышында һәлак булган дусым, майор Алексей Паращенко истәлегенә.

Берлин.
Гүя җир тетрәгән монда —
Җимерелгән соры өйләре.
Монда минем басып йөргән ташлар
Һәм мин аткан пуля эзләре.
Уйлаганда, күргән башка сыймый,
Күпме юллар үттек — кичердек.
Ләкин бер юл — җиңеп кайту юлы
Берлин ташларына китерде.
Кайтам хәзер...
Шушы урамнарның
Тукталам да һәрбер чатына,
Хәтерлимен барын...
　　Һәм баш иям
Монда үлгән дуслар хакына.

* * *

Дуслык, дуслык.
Яшәү яме өчен
Кешеләрдә кайнап туасың,
Гомер кебек үзең кадерлесең,
Язлар кебек җылы буласың.
Юк, Алексей!
Түгел идек икәү
Бер анадан булган туганнар.

Украинаңны өзелеп сөя идең,
Ә мин килгән идем Уралдан.
Безнең туган өйләр арасында
Күпме юл бар, күпме борылма!
Юлларны һәм безне ил язмышы
Бергә кушты сугыш кырында.
Окоптагы якын дуслык өчен
Айлар, еллар кирәк түгелләр,
Бер генә көн бергә яшәсәң дә,
Дуслашасың икән гомергә.
Госпитальдән качып, аксый-аксый,
Син ашкынып килдең бу җиргә.
Һәм урамда, мине кочып алып,
Әйттең: «Дускай, җиттек Берлинга»!
Ул куллар юк, ләкин күкрәгемдә
Алар көчен тоям һаман да;
Син шат идең, шул чак күзләреңдә
Күрдем бәхет, теләк, хыяллар...
Ага һаман шул ук Шпрее,
Ята шул ук урам ташлары.
Аккан каның яңгыр юган хәзер,
Тик йөрәктә аның таплары.
Ә нигә соң дәваланып бетми
Килдең икән, сизми үлемне...
Юк, йөрәгең андый түгел иде,
Әйбәт иде синең күңелең.
Кайтам, дускай! Дөнья матурлыгын
Синсез генә инде күрермен.
Ләкин беләм:
Икәү эшләсене
Мин эшләрмен хәзер берүзем.
Үтәр еллар,
Кемдер галим булыр,
Безнең үткәннәрне тикшереп.
Һәм хәтерләр галим бәхет өчен

Гомерен биргән гади кешене.
Дуслык, дуслык!
Яшәү яме өчен
Кешеләрдә кайнап туасың,
Гомер кебек үзең кадерлесең,
Кояш кебек кайнар буласың.

Йөрәгемә якын бары да

Башка бәхет миңа кирәк түгел —
Аякларым баса бу җиргә!
Аккош күлсез тора алмаган кебек,
Мин зарыгып йөрдем чит илдә.
Кырлар —
Минем тәпи баскан җирләр —
Хыяллардан иркен киңлеге.
Һәм нинди көч,
Гайрәт сулый монда,
Ул матурлык, ул ямь дисеңме!
Таныш җирләр баса күз алдыма,
Чәчкәләрен күрәм тагын да,
Алар белән бәхетем бергә үсте —
Йөрәгемә якын бары да.
Алар миңа мең җыр матурлыгы,
Шуңа җырлар, җырлар ургыла,
Җырсыз йөрәк гөлсез бакча кебек,
Ә ул гөлләр үскән юлыма,
Алар кушыла йөрәк җырыма.
«... Күкрәп торган зәңгәр кырлар,
Үткән юлларым буйлап,
Берлиннан Варшава аша
Мин кайтам сезгә урап.
Әй! Кайтам, кайтам илемә, —
Илкәем ил генәме;
Сөреп, тырмалап йөргән

Җиркәем җир генәме».
Җир генәме бу җир?
О Россия!
Туган иле Бөек Ленинның;
Кешелеккә яңа Ломоносовларны,
Күпме акылларны син бирдең.
Җир генәме бу җир?
О Россия!
Бөек дуслыкның син Ватаны.
Күпме төрле халык —
берсен берсе
Якын туган, дус дип атады.
Шушы дуслык
Очар канат куйды,
Ун гомерне бергә китерде.
Һәм ул дуслык,
Утта яндырмыйча,
Берлин ташларына җиткерде.
Прометейлар, авыр газапларны
Кичергәндә Зоя берүзе,
Дошманнарга — үлем,
Ә Зояга
Үлмәс гомер бирде дус сүзе.
Күрәм, илем, янган туфрагыңны,
Сугыш баскан эзләр калдыгын,
Окоп түгел хәзер,
ә туачак
Гигантларга нигез казырмын.
Башка бәхет миңа кирәк түгел —
Аякларым баскач биргә,
Күк күкрәвен тәү ишеткән кебек,
Мин аунадым ятып җиремә.
Еларга да хәтта ризамын мин,
Күз яшьләрем утта кипсә дә,

Ул тик бары сине сөйгәнлектән,
Йөрәк төпләрендә бетмәгән.
Атам тире синең туфрагыңда,
Һәм ул йөргән сукмак эзләре...
Ул эчкән су ага,
Ул утырткан
Агачлар да һаман үсәдер...
Адым белән сине атлап чыктым,
Күпме окоп казыдым үзеңдә...
Кочагыма туфрагыңны кыстым
Саклап калыр өчен үлемнән.
Һаваң кебек минем күңелем саф,
Агыйделдәй якты уйларым;
Киңлегеңдә тормышымның яме,
Киләчәкнең гомер юллары.
Солдат булып,
Сине генә уйлап,
Нинди җирләр үтеп йөрмәдем.
Бар дөньяны чак чыкмадым урап,
Сиңа охшаган җир күрмәдем.
Синдә генә мин бәхетле булдым,
Үссәм дә гел ятим, атасыз;
Ата-анасыз яшәүләре мөмкин,
Мөмкин түгел яшәү Ватансыз!

1947

АГЫЙДЕЛДӘ АҠ ТОМАН

Агыйделдә ак томан,
Пароход тавышлары;
Дымлы керфекләр шикелле
Ярында камышлары, —
Пароход тавышлары.

Агыйделдә ак томан,
Ат кешни болыннарда;
Ат эзләп йөргән эзләрем
Ҡалган шул урыннарда,
Чык төшкән болыннарда.

Агыйделдә ак томан,
Борылган Идел белән;
Нигә шулкадәр якынсың,
Әй туган Иделгенәм!
Йөрәгем синең белән.

1960

СӨЮ СҮЗЛӘРЕ

*
* *

Көн җилләсә, аны я аязга,
Я яңгырга, диләр, кешеләр.
Күңелем тыныч түгел, синең өчен
Ул да җилли кебек... Ул җилләр
Ни өчендер, аязгамы икән,
Яңгыргамы икән?— Белмимен;
Икесе дә әйбәт: тормышның мин аяз,
Яңгырлы да булуын телимен.

1951

ТУЙ ТАБЫНЫНДА

Ике елга бергә кушылып акса,
Киң һәм тирән була сулары;
Теләгем шул: ярларыннан ташып
Чыксын сезнең гомер юллары.

Мин күтәргән шушы бокал кебек,
Керсез, якты булсын һәр күңел;
Тормыш матур бүгенге туйсыман,
Ләкин тормыш һич тә туй түгел.

Диңгез кебек аның ярлары киң,
Давыллы да, тын да була ул;
Ләкин диңгез җил юкта да шаулый,
Шундый булсын тормыш сулавы.

1947

СӨЮ

Җир тетрәтеп, язның бер көнендә
Күк күкрәде яшен артыннан;
Иркен сулап җир яшәрде шул чак,
Күктән тамгач тәүге тамчылар.

Сөю, сөю! Шундый күкрәү булып,
Күз алдымда кинәт яшьнәдең,
Һәм гомергә, күкрәгемдә күкрәп,
Көч һәм шатлык булып яшәдең.

Яңгырдан соң, кояш балкыганда,
Саф булгандай җирнең сулышы,
Бәхетле уй, илһам һәм бетмәс дәрт
Күкрәгемдә тора тулышып...

Җир өстендә бөтен нәрсә шиңә
Яңгырсыз һәм күкрәү-яшенсез —
Йөрәгендә сөю йөретмәгән
Кеше ярлы һәм иң бәхетсез.

1949

ӘЙТЕЛМӘГӘН МӘХӘББӘТ

Уралда масаеп тора
Кыя тын гына;
Күрдем: аңа бер ак болыт
Килде шым гына.

Килде дә озак йөрде ул
Аны тирәләп;
Я түбән төште, я өскә
Менде үрмәләп.

Я торды туктап кыяга
Караган төсле;
Бервакыт таудан чак кына
Салкын җил исте.

Очты болыт... Ташта калды
Салкын дым гына,
Һәм болытның бөтен эзе
Булды шул гына.

1949

КӨМЕШ АРБА

Юл буйлары гөлгә тулган,
Ике япь-яшь кеше юлдан
Атлый тын гына;
Алларында — ап-ак арба,
Ә арбада япь-яшь бала
Йоклый тын гына.

Аңа карап йотылганнар,
Икесе дә тотынганнар
Көмеш арбага;
Карашлары нурга тулган,
Әйтерсең лә, кояш кунган
Шушы арбага.

Мин аларны беләидем,
«Әй матур пар!» — дия идем
Күргән чагымда;
Сокланганмын алданрак,
Алар бүген матуррак —
Арба янында.

Бабайне дә калдым күреп,
Оядагы кошчык кебек
Ята тын гына;
Көмеш арба җем-җем итә,
Ә ул һаман черем итә,
Ята тын гына.

Үтелгән юл — кыска ара,
Тик арбада үтә бала
Тәүге юлларны;
Бервакыт ул үсеп җитәр,
Озын-озын юллар үтәр,
Бизәп дөньяны.

Юл буйлары гөлгә тулган,
Ике япь-яшь кеше юлдан
Атлый тын гына;
Алларында — ап-ак арба,
Ә арбада япь-яшь бала
Йоклый тын гына.

1950

ИКЕ ЕЛГА

Ике елга ике тау битеннән
Кышын, җәен җем-җем ялтырап,
Тау астына төшкәч, икәү бергә
Гомер буе кушылып актылар.

Тик бер заман каты күкрәү үтте,
Тау ярылды яшен утыннан;
Елгаларның берсе башка якка
Агып китте башка юл белән.

Акты елга, яңа юллар салып,
Үзенә ят җирләр аркылы;
Үтте дала һәм урманнар аша,
Үтте ерып таулар ташлыгын.

Күпме каршылыклар очратса да,
Акты, акты... туктап тормады.
Урап-урап, эзләп килеп тапты
Ялгыз калып аккан елганы.

... Иркәм, мин дә сине сагынып
кайттым,
Кайттым үтеп ярты дөньяны.

1948

АГЫЙДЕЛ АША

(Шаян җыр)

Ярларына сыя алмый
Агыйдел таша;
Кыз һәм егет чыгып килә
Агыйдел аша.
Егет җырлап ишкәк ишә,
Тырыша егет;
Ул тырышмас иде дә соң,
Кызы матур бит.

Менә бер чак гүя егет
Кинәт йоклады;
Идел уртасына җиткәч,
Көймә туктады.
Егет килде кыз янына
Һәм кочып алды;
Көймә, канатсыз кош кебек,
Торды да калды.

Тик Агыйдел аңламады
Кызны, егетне;
Көймәне түбән агызып
Алды да китте.
Егет белән кыз алдында
Дөнья буталды;
Агыйделдә ялгыз көймә
Күздән югалды.

Менә кояш тау артына
Батып та бара;
Безнең танышлар да чыккан
Кайтырга таба.
Егет яр читеннән бара
Ак-кара күрми,
Борынгы бурлак шикелле
Көймәне сөйри.

Ә кыз утыра көймәдә:
«Сөйрә әйдә!» — дип;
Башына төшкәч, тарта егет,
Кызы матур бит.
Адәм башы ниләр күрми —
Манма су булган;
Бер рәхәтнең бер михнәте
Була шул, туган.

1952

МӘХӘББӘТ

Бөтен нәрсә балкып китте кебек,
Һәм хәл алды кебек уйларым.
(Чиксез итәр идем икәү бергә
Булган минутларны, юлларны.)

Бөтенесе бергә килде миңа:
Җәе, көзе, кышы, язы да;
Күңелем шат, кулым эшкә бара,
Шигырьләрем җиңел языла;

Таулар күчерерлек көч тоям мин,
Артты сабырлыгым, түземлек,
Кеше алдында сынатасым килми,
Җыйнак йөретәсем килә үземне;

Аның белән горурланамын да,
Ачыклыгы арта йөземнең;
Матур хыял баса, Кабат уйландыра:
«Болар бары да бушка түгелме?..»

Уйлар... Уйлар... Оча төнге йокы:
Үзе кыен, үзе бик рәхәт...,
Ахры, шулдыр инде мәхәббәт.

1951

КӨЗГЕ ТӨНДӘ

Яңгыр катыш ябалак кар
Ява буранлап;
Һәм бер бабай кайтып килә
Төнен урамнан.

Чатыр астына бөрешкән
Тавышсыз-нисез;
Ул үз-үзен тиргәп килә:
«Әй син, карт юньсез.

Шундый төнне өйдә генә
Ятсаң ни була...»
Бабай атлый алга табан,
Җил артка куа.

Кайта бабай, күрә бабай
Шундый бер төндә;
Бер кыз белән егет тора
Капка төбендә.

Өсләре җепшек кар гына,
Беткәннәр катып;
Бабай кырын карап куйды:
«Тапканнар вакыт...»

Әллә туктаусыз ачудан
Ул тәмам туйды.

Бераз баргач, борылды да
Елмаеп куйды:

«Аларга бит таш яуса да
Түгел берни дә;
Их, яшьлек!— диде бабабыз,—
Торсыннар әйдә!»

1952

ЕЛ БАШЛАНА

Мин дусларым арасында шушы
Яңа елны синсез каршы алам;
Менә аның тәүге минутлары...
Ә ул нинди матур башлана!

Һәм ул менә, менә күз алдымда,
Ул саф, ул шат, матур җыр кебек;
Син дә миңа әле башланмаган,
Алда торган яңа ел кебек.

Ә мин синсез... Аның авырлыгын
Үзем генә тоям, ахыры.
Ләкин шатмын, ә бит хәтәр көннәр
Аермыйлар безне, акыллым.

Җиребездә бернинди юк давыл,
Ут һәм сөрем — ә тик саф һава.
Ак күгәрчен мамыгыдай ап-ак
Тыныч кына тышта кар ява.

Башлана ел... Тыныч хезмәт елы —
Ул саф, ул шат, матур җыр кебек!
Син дә миңа әле башланмаган,
Алда торган яңа ел кебек.

1952

«АЛЕНУШКА»

В. М. Васнецовның «Аленушка» дигән рәсеме минем бүлмәдә күптән инде эленеп тора.

Тормышында юк үзгәреш, диләр,
Бара, диләр, дөньяң тип-тигез.
Тик белмиләр: дөнья көтеп яту
Аленушка белән икебез.

Ләкин дөнья тигез бармый әле —
Уртак тел юк... Ярый мин түзем.
Ул да боек, мин дә шат түгелмен,
Ул да ялгыз, мин дә берүзем.

Ул әкият кызы. Ә мин кем соң? —
Охшаш безнең бары бала чак.
Мин туганчы шулай ул яшь булган,
Мин үлгәч тә шулай калачак.

Шуңа көнләшәм мин. Ләкин үзем
Аптырыйм шул кайчак ул кызга.
Боек кебек минем уйчанлыкка,
Ә шат булсам — минем шатлыкка.

Соңлап кайтсам, үпкәләгән кебек,
Аңламый ул минем күңелне;

Аленушкам, без гел икәү бергә.
Сине генә сөям түгелме?!

Уртак тел юк безнең арабызда —
Шуңа, ахры, безгә күңелсез.
Мин китәрмен бер чак, син калырсың,
Син калырсың — син бит үлемсез...

1959

ТАР СУКМАК БУЙЛАП

Арыш басуы юлында
Аны култыклап алдым;
Ул тәгәрмәч эзе белән,
Мин ат эзеннән бардым.

Авылга килеп җитәрәк,
Юл китә бераз урап;
Без туры чыкмакчы булдык
Икәү тар сукмак буйлап.

Сукмак инде юл түгел шул:
Юк ат, тәгәрмәч эзе;
Парлап килгәннәргә бик тар,
Җайсыз да икән үзе.

Кыз кешегә мин юл бирдем:
«Алдан китегез», — дидем;
«Алдан сез китегез», — дип ул
Артыма чыкты минем.

Башта ни эшләргә белми,
Бераз югалып калдым;
«Алай булгач, киттек», — дидем,
Кабат култыклап алдым.

«Шулкадәр якын килмә, — ди, —
Син бит тик якын таныш»...

«Юк, — мин әйтәм, — сукмак тар бит,
Таптала, — димен, — арыш»...

Без киләбез... мин шатланам
Сөйгәнем барлыгына,
Арышның тапталмавына,
Сукмакның тарлыгына.

1953

ҠАРЛЫГАЧ

«Ҡара карлыгач микән лә, — диләр, —
Әллә микән ҫары сандугач?»
Ул, дим, минем гомерҫмә язлар
Алып килгән кара карлыгач.

«Бер карлыгач яз китерми», — диләр,
Моны беләм, беләм үзем дә:
Ул берүзе алып килде миңа
Язын, җәен, кышын, көзен дә.

1959

ДИМ ЯРЫНДА, УЧАК ЯНЫНДА

Бер карарга сиңа курка идем,
Бер карарга сиңа ул чакта;
Менә бүген без икәүдән-икәү
Ашлар пешерәбез учакта.

Элек тә бит шул ук Дим иде.
Син дә бит — син, мин дә — мин идем.

Карыймын да сиңа хәйран калам,
Без нинди дус, нинди якыннар.
Элегрәк нигә янмаган соң
Шушы учак, шушы ялкыннар?!.

Элек тә бит шул ук ут иде,
Син дә бит ут, мин дә ут идем.

Тик син бүген кайтыр чакта гына,
Су сорагач, мин су китердем;
Шул су белән янган учагымны,
Ут чыгар дип, куркып сүндердем.

Безнең язмыш менә шул икән:
Беребез ут, беребез су икән.

1957

КӨЗГЕ ЯФРАКЛАР

Көзге урман... җиргә яфрак яуган.
Алтынланган бөтен тирә-як;
Баскан саен миңа кыштыр-кыштыр
Нидер сөйли кебек һәр яфрак.
Ни сөйлиләр алар? Беләм, беләм —
Барысына алар шаһит бит:
Без урманда тик икәүдән-икәү
Шашып йөрдек... Әйе, шаштык бит...
Без икәүдән-икәү генә идек,
Ләкин бергә идек без гелән:
Һәрбер агач, һәрбер яшел яфрак,
Һәрбер чәчәк, туфрак, һәр үлән.
Икәү онытылган минутларда,
Авып калган чакта үләннәр,
Безне сөеп, сер саклап бит алар
Яшерделәр бар ят күзләрдән.
Барыбыз да бергә сөйләштек без,
Барыбыз да гүя йөгәнсез;
О юктыр ла сөю, юктыр хәтта
Чәчкәсез һәм туфрак-үләнсез.
Көзге урман... җиргә яфрак яуган.
Алтынланган бөтен тирә-як;
Адым саен һаман кыштыр-кыштыр
Нидер сөйли миңа һәр яфрак.
Мин аларны таптап үтәм... ләкин
Мин гомергә сөеп туймадым;
Кичерегез, яфракларны җиргә
Мин коймадым! Юк, мин коймадым!

1960

КӨТЕЛМӘГӘН ЯҢГЫР

(Бер кыз хикәясе)

Яңгыры да көтмәгәндә
Яшьнәп-күкрәп килде;
Җыелмаган покосларым
Бүген кипмәстер инде.
Йөгердем агач төбенә,
Өстем чыланды тәмам;
Ә яңгыр җилләп-давыллап
Коя да коя һаман.
Чү, ни күрәм — яшен ташы
Булып ул төштемени?
Я булмаса, җирдән чыгып,
Алдыма үстемени?
Тора елмаеп каршымда —
Килгән ул яннарыма;
Уф, оялам — күлмәгем дә
Ябышкан тәннәремә.
Нигә ышыкландым икән
Яңгырдан куркып, җүләр,
Ул кулымнан тотып алды,
Мин әйттем: «Җибәр, җибәр!»
Күзләренең карашлары,
Әйтерсең, ала өтеп...
Ә мин күпме йөргән идем
Шул карашларны көтеп.
Әй бу шатлыклы минутлар —

Йөрәккә дәвамыни?!
Яңгыр түгел, бетмәс бәхет
Өстемә явамыни!

Яңгыр, яңгыр... күкрәп килеп,
Җирне чылатып үтте.
Ә ул билләремнән кысып,
Мине җылатып үпте.

1959

АЛМАЛАР ПЕШКӘН ЧАКТА

Алмалар пешкән чакта,
Мин кайттым туган якка.

Кайда карама — гел бакча,
Бер бакча безнең урам;
Иң матуры күршебездә —
Сокланып карап торам.
Карап торам. Кемдер миңа
Күз сала читән аша;
Бәй, бу безнең күршебезнең
Кече кызы лабаса.
«Һай! — дидем. — Безнең күршедә
Кызлар да үскән икән.
Авыз итәргә мөмкинме,
Алмагыз пешкән икән?..»
Күзләре усал карады,
Кысылды иреннәре.
«Һе!» — диде дә бакчадан елт —
Башка ул күренмәде.
Кич булды, кояш баеды,
Ә мин үземне тетәм:
«Ахмак», — димен... ләкин миңә
Бакчага чыксам иртән,
Мин ни күрәм: «Төнен, — димен, —
Алмаларга ни булган?
Безнең якка, читән аша
Шулкадәр күп коелган!..»

Кып-кызыл алма кулымда,
Үзем ут тотам кебек;
Үзем авыз иткән булам,
Үзем ут йотам кебек.

Шәп икән безнең якта
Алмалар пешкән чакта.

1960

ӨЙЛӘРЕНДӘ УТЛАРЫ БАР

Өйләрендә утлары бар,
Күз алмый торган булам;
Тәрәз төпләренә килеп,
Тамагым кырган булам.
Тәрәзәләре ачык та,
Корылган пәрдәләре;
Кайчак ни көнгә калабыз
Без — алла бәндәләре.
Көндез эштә күрәм дә бит,
Күрүдә хикмәтмени?!
Көндезләр ул хезмәт өчен,
Мәхәббәт хезмәтмени!
Һәрнәрсәнең үз вакыты,
Шуңа да торган булам;
Тәрәз төпләренә килеп,
Тамагым кырган булам.
Чү! Пәрдә селкенеп куя,
Күнелем шатлык тоя;
Юк! Әнкәсе тәрәзләрен
Шап итеп ябып куя.
Аңламассың ана халкын,
Үзе кыз булгандыр бит!
Кайчандыр аңа да берәү
Тамагын кыргандыр бит!
Җиткән кыз — пешкән җимеш тә,
Тик саклап буламыни?
Һәрнәрсәнең үз вакыты,

Их, саклап буламыни!
Алай булса, мин сызгырып
Сүндерәм утыгызны,
Үзем белән алып китәм
Күтәреп йортыгызны.

1960

ЛӘЛӘ

(Сатирик җыр)

Мин бер кыз белән таныштым:
Исеме Ләлә, Ләлә;
Төсе-башы, буе-сыны —
Әл-лә-лә-лә-лә-лә-лә!

Минем өчен дөньяда бер,
Бер генә Ләлә, Ләлә;
Күп тә үтми ире булдым —
Әл-лә-лә-лә-лә-лә-лә!

Китте тормыш — типтерәбез:
Шат минем Ләлә, Ләлә;
Ике дөнья — бер *мәрҗә лә* —
Трал-ля-ля-ля-ля-ля-ля!

Кесә юкарды да куйды,
Башыма төште бәла;
Өйгә дә кайтмый башлады
Сылуым Ләлә, Ләлә.

Күрмәгәнемне күрсәтте
Туйганчы Ләлә, Ләлә;
Сезнең бәла бәламени,
Вәт минем бәла бәла —
Әл-лә-лә-лә-лә-лә-лә!

1958

ЭЧТӘЛЕК

Туган ил турында сүз 3

Тамчылар

Тамчылар 4
Безнең урамнарда 5
Котелок 6
Дуслар 8
Медаль 9
Александр Матросовка — пароходка һәм солдатка 11
Мин китмәкче булдым 14
Шагыйрь тавышы 16
Мендем Урал тау башына 18
Туган калама җыр 19
Кичке Агыйдел 21
Һәйкәл турында баллада 22
Җилкән 24
Ике вышка 25
Бала 26
Миләш 27
Уйланулар 29
Шобага 31
Шулдыр инде 33
Муел 34
Кыз һәм ил 36
„Яз! Яз!“ — диләр 38
Кичер мине 39
Үпкә 40
Кайту 43
Агыйделдә ак томан 50

Сөю сүзләре

*** Көн җилләсә 51
Туй табынында 52
Сөю 53
Әйтелмәгән мәхәббәт 54
Көмеш арба 55
Ике елга 57
Агыйдел аша 58
Мәхәббәт 60
Көзге төндә 61
Ел башлана 63
„Аленушка" 64
Тар сукмак буйлап 66
Карлыгач 68
Дим ярында, учак янында 69
Көзге яфраклар 70
Көтелмәгән яңгыр 71
Алмалар пешкән чакта 73
Өйләрендә утлары бар 75
Ләлә 77

Н. Наджми

СЛОВА ЛЮБВИ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Б. М. Альменов*
Техник редакторы *Ф. Х. Габдуллаҗанова*
Корректоры *С. В. Насыйбуллина*

Наборга бирелде 17|X-61 ел. Басарга кул куелды 21|II-62 ел.
Кэгазь форматы $70 \times 92^1/_{32}$. Учет.-изд. 2,1 таб. Басма табак 2,5 (293)
ПФ 03035. Заказ В-407. Тираж 5000 экз. Бәясе 11 тиен.

ТАССР Культура министрлыгының „Татполиграф" типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

Бәясе 11 тиен.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1962